ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ТАТАРСКО-ТОЛКИШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЧИСТОПОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАТАР ТАЛКЫШЫ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422961, Республика Татарстан,
Чистопольский район,
село.Татарский Толкиш, ул.Советская,
дом 4

422961, Татарстан Республикасы,
Чистай районы, Татар Талкышы авылы,
Совет урамы, 4 нче йорт.

тел. 884342 3-32-23, e-mail:Ttolk.Ctp@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2025 елның 26 феврале №5

Чистай муниципаль районы Татар Талкышы авыл җирлеге Башкарма комитетының «Чистай муниципаль районы Татар Талкышы авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2019 елның 20 декабрендәге 20 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Чистай муниципаль районы Татар Талкышы авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Чистай муниципаль районы Татар Талкышы авыл җирлеге Башкарма комитетының «Чистай муниципаль районы Татар Талкышы авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2019 елның 20 декабрендәге 20 номерлы карары белән расланган Чистай муниципаль районы Татар Талкышы авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1. 2.2 пунктның «в» пунктчасында "Бүлектә дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү вариантлары булырга тиеш, аларда гомуми билгеләр белән берләштерелгән мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләренә, шул исәптән алар сорап мөрәҗәгать иткән дәүләт яки муниципаль хезмәт нәтиҗәсенә карата да, күрсәтелгән хезмәтләрне күрсәтү тәртибе кертелергә тиеш" сүзләрен "Федераль законның 13 статьясындагы 13_1-15 өлешләрендә күрсәтелгән административ регламентларны әзерләү һәм раслау тәртипләрендә каралган

очракларда күрсәтелгән бүлек административ регламент структурасына кертелмәскә мөмкин" сүзләренә алмаштырырга;
1.2. 2.4 пунктның «о» пунктчасында "документлар" сүзеннән соң "һәм (яисә) мәгълүмат" сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны авыл җирлеге торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларына һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, шулай ук Чистай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырырга.

Татар Талкышы авыл җирлеге
башлыгы М.М. Вәлиев